# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге Яңа Айман торак пунктында 2025 елда
гражданнардан үзара салым кертү турында

**29.11.2024 ел** **№ 20**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Яңа Айман торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Яңа Айман торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

1) Яңа Айман торак пунктында һәйкәлләр төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү(Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга обелиск киртәсен урнаштыру өчен материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Әтрәкле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http://menzelinsk.tatarstan),хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы ____________ А.М. Гильмуллин